| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2023 ел № 28/9

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру Тәртибен раслау турында

«Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 8 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру Тәртибен кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ... РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
28/9 Карарына кушымта
6 декабрь, 2023 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру Тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип «Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 8 пункты, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм янәшәсендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру тәртибенә һәм срокларына бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба - Тәртип).

2. Иҗтимагый фикер алышур кешенең уңай яшәү шартларына хокукын үтәү максатыннан үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуда катнашу ихтыяри һәм ирекле булып тора.

3. Иҗтимагый фикер алышу дигәндә Тәртиптә муниципаль берәмлек халкының муниципаль берәмлек территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату гамәлгә ашырылганда хокуклары һәм мәнфәгатьләре кагылырга мөмкин булган башка кызыксынучы затларның фикерләрен ачыклау буенча катнашу рәвеше аңлашыла.

4. Иҗтимагый фикер алышу максаты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә түбәндәгеләр белән чиктәш территорияләр чикләрен билгеләү өлешендә алкоголь продукциясен ваклап сатуга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салудан гыйбарәт:

1) белем бирү оешмалары биләгән һәм (яисә) файдаланган биналар, төзелешләр, төзелмәләр, корылмалар (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш);

2) балигъ булмаганнарга белем бирүне гамәлгә ашыручы оешмалар биләгән һәм (яисә) файдаланган биналар, төзелешләр, төзелмәләр, корылмалар;

3) эшчәнлекнең төп (устав) төре буларак медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яки төп (устав) эшчәнлеге белән беррәттән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән

тыш, медицина эшчәнлеге алып баручы оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр карамагындагы һәм (яисә) алардан файдалана торган биналар, төзелешләр, төзелмәләр, корылмалар;

4) вокзаллар;

5) хокуклары билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек объектлары булган спорт корылмалары;

6) «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган югары куркыныч чыганакларын ачыклау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 декабрендәге 1338 номерлы карары белән билгеләнгән югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннар;

7) күпфатирлы йортлар.

5. Иҗтимагый фикер алышу алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган чиктәш территорияләрнең чикләрен билгеләү яки элек билгеләнгән чикләрне юкка чыгару (киметү) турында муниципаль хокукый акт проектына (алга таба - муниципаль хокукый акт проектына, җәмәгать фикер алышулары предметына) карата гамәлгә ашырыла.

## 2 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар

6. Иҗтимагый фикер алышуда Россия Федерациясенең унсигез яшькә җиткән гражданнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, төрле һөнәри һәм социаль төркем вәкилләре, шулай ук иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылган яки кагылырга мөмкин булган затлар катнаша.

## 3 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуны оештыру тәртибе

7. Муниципаль хокукый акт проекты буенча иҗтимагый фикер алышу электрон формада, материалларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча https://nabchelny.ru/ (алга таба - рәсми сайт) урнаштырып гамәлгә ашырыла.

8. Иҗтимагый фикер алышу Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Иҗтимагый фикер алышу уздыру турындагы карарда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу предметы;

2) иҗтимагый фикер алышу уздыру датасы, срогы;

3) муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес.

9. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән алып егерме көннән дә соңга калмыйча иҗтимагый фикер алышу үткәрү турындагы карар, муниципаль хокукый акт проекты белән бергә рәсми мәгълүмат чыгынакларында басылып чыгарга һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

10. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү процедурасы түбәндәге этаплардан тора:

1) иҗтимагый фикер алышу предметы буенча мәгълүмати материалларны рәсми мәгълүмат чыгынакларында һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру;

2) беркетмә әзерләү;

3) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү.

11. Иҗтимагый фикер алышу дәвамлылыгы унбиш календарь көн тәшкил итә.

12. Иҗтимагый фикер алышу әзерләү һәм үткәрү составы Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелешләргә, корылмаларга, төзелмәләргә урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу үткәрү комиссиясе (алга таба - Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Комиссия компетенциясенә түбәндәге сораулар керә:

1) иҗтимагый фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыюны гамәлгә ашыру;

2) кирәкле белешмә материаллар әзерләү;

3) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне карау;

4) иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү.

14. Комиссия рәисе:

1) комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

2) иҗтимагый фикер алышуны әзерләү һәм уздыру планын раслый;

3) әлеге Тәртип нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Тавышлар саны тигез булганда рәис тавышы хәлиткеч була.

## 4 бүлек. Иҗтимагый фикер алышуда карала торган проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне кабул итү

15. Иҗтимагый фикер алышуда каралырга тиешле муниципаль хокукый акт проектын һәм мәгълүмати материалларны урнаштыру чорында физик һәм юридик затлар, иҗтимагый оешмалар карала торган муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне иҗтимагый фикер алышуны билгеләү турындагы карарда күрсәтелгән электрон почта адресы аша Комиссиягә кертергә хокуклы.

Муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр физик һәм юридик затлар, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән форма нигезендә рәсмиләштерелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү иҗтимагый фикер алышуны билгеләү турында мәгълүматны һәм иҗтимагый фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проектын бастырып чыгару көненнән башлана һәм иҗтимагый фикер алышуны уздыру срогы ахырына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

16. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр иҗтимагый фикер алышу предметына туры килергә тиеш. Искәрмәләр һәм

тәкъдимнәр иҗтимагый фикер алышу предметына туры килмәсә, Комиссия мондый тәкъдимне яисә искәрмәне иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә теркәми.

17. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр иҗтимагый фикер алышуда катнашучының дөрес булмаган мәгълүмат бирүе факты ачыкланган очракта каралмый.

Иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң кергән искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр, аноним искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр, цензурасыз яисә мыскыллаулы искәрмәләр һәм (яисә) тәкъдимнәр каралмый һәм исәпкә алынмый.

18. Тәртипнең 15 пункты нигезендә кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлергә, Тәртипнең 17 пунктында каралган очрактан тыш, Комиссия тарафыннан, мәҗбүри каралырга тиеш.

19. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында түбәндәге мәгълүматлар тапшыра (мондый мәгълүматларны раслый торган документларны теркәп):

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) урынының адресы − физик затлар өчен;

2) исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен.

20. Иҗтимагый фикер алышуда катнашучыларның персональ мәгълүматларын эшкәртү «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

21. Проектка кертелгән тәкъдимнәр Комиссия әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, башка муниципаль хокукый актларга туры килү предметына өйрәнелә.

## 5 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе

22. Комиссия иҗтимагый фикер алышу беркетмәсен әзерли һәм рәсмиләштерә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә имза кую датасы;

2) иҗтимагый фикер алышу уздыру срогы турында басылып чыккан хәбәрдә булган мәгълүмат, аны бастырып чыгару датасы һәм чыганагы;

3) иҗтимагый фикер алышуда катнашучылардан кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр.

23. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә түбәндәге мәгълүматлар белән иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар исемлеге теркәлә:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәлү) урынының адресы − физик затлар өчен;

2) исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен.

24. Иҗтимагый фикер алышу үткәрү беркетмәсе иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә төзелә.

## 6 бүлек. Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә

25. Иҗтимагый фикер алышу беркетмәсе нигезендә Комиссия әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма нигезендә иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерли.

Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенә имза куелган көннән алып өч эш көне эчендә әзерләнә.

26. Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмәдә булырга тиеш:

1) иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмәне рәсмиләштерү датасы;

2) иҗтимагый фикер алышуда каралган муниципаль хокукый акт проекты исеме, иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар саны турында мәгълүмат;

3) аның нигезендә иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләнгән иҗтимагый фикер алышу беркетмәсенең реквизитлары;

4) кергән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр эчтәлеге. Иҗтимагый фикер алышуда берничә катнашучыдан бер үк төрле тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кергән очракта, мондый тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерү рөхсәт ителә;

5) иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрнең һәм искәрмәләрнең максатка ярашлылыгы яисә максатка ярашсызлыгы турында Комиссиянең дәлилләнгән тәкъдимнәре һәм иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре.

27. Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә кабул ителгән көннән алып 14 эш көне эчендә Комиссия аны рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында комиссия бәяләмәсе рекомендация характерына ия.

28. Иҗтимагый фикер алышу материаллары Башкарма комитетта 5 ел дәвамында сакланырга тиеш.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру Тәртибенә 1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Ф.Ш. Салаховка

Ф.И.А.и. ___________________________
___________________________________
Туу датасы____________________
Яшәү урыны адресы____________
___________________________________
___________________________________
Электрон почта_________________
___________________________________

Муниципаль хокукый акт проекты буенча иҗтимагый фикер алышуда катнашуга гариза
«_____________________________________________________________________»

Проект буенча тәкъдимнәр:__________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
________
Проект буенча искәрмәләр:__________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Мин,
_______________________________________________________________________,:
______________________________________________________________________________
«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге

Башкарма комитетында «___________________________________________
_______________________________________________________________________»
муниципаль хокукый акты проекты буенча иҗтимагый фикер алышуүткәрү барышында түбәндәге шәхси мәгълүматларымнан: Ф.И.А.и, туган ел, яшәү урыны адресы, электрон почтадан файдалануга, эшкәртүгә һәм саклауга ризалык бирәм.

Әлеге ризалык _____________башлап, ________________ кадәр гамәлдә.
Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире кайтару язма гариза нигезендә мөмкин.

Ф.И.А.и._____________
Имза______________
Дата _________________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча иҗтимагый фикер алышу уздыру Тәртибенә 2 нче кушымта

20__ елның «___»__________20__ елның «___»__________ кадәр уздырылган

________________________________________________________________________________

_______________ (муниципаль хокукый акт проектының исеме )_________________

иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында бәяләмә

Катнашучылар саны ______

Беркетмә реквизитлары ___________________________

| № т/б | Тәкъдим (искәрмә) эчтәлеге | Карау нәтиҗәсе (исәпкә алынган/кире кагылган, нигезләнгән) |
|---|---|---|
| | | |

Максатка ярашлы булуы/булмавы турында Комиссия тәкъдимнәре

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Комиссия рәисе

имзасы _______________________ Ф.И.А.и.